КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 20 июль г.Казань № 622

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 315 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 663 нче; 2006 ел, 2 май, 216 нчы; 2008 ел, 27 июнь, 449 нчы; 2009 ел, 13 июль, 491 нче; 2010 ел, 11 июнь, 465 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1035 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 29 август, 724 нче; 2012 ел, 8 сентябрь, 761 нче; 2013 ел, 19 март, 190 нчы; 2014 ел, 1 февраль, 54 нче; 2014 ел, 11 март, 150 нче; 2014 ел, 16 май, 325 нче; 2014 ел, 26 декабрь, 1042 нче; 2015 ел, 30 июнь, 472 нче; 2016 ел, 13 май, 301 нче; 2016 ел, 22 октябрь, 769 нчы; 2016 ел, 30 ноябрь, 880 нче; 2017 ел, 22 май, 295 нче; 2018 ел, 9 апрель, 223 нче; 2018 ел, 11 июль, 562 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1098 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1291 нче; 2020 ел, 6 март, 177 нче; 2020 ел, 12 июнь, 486 нчы; 2021 ел, 18 май, 345 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «1 133,5» саннарын «1 154,7» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

3.2 пунктның егерме икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01*);»;

3.3 пунктта:

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы рәсми физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планнарын (шул исәптән «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексын тормышка ашыру буенча физкультура чараларын һәм спорт чараларын үз эченә алган) эшләү, раслау, оештыру һәм тормышка ашыру;»;

егерме җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган республика рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын һәм муниципальара рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган мөһим рәсми физкультура чаралары һәм спорт чаралары исемлеген ел саен формалаштыру һәм раслау;

Татарстан Республикасында спорт төрләрен үстерү программаларын эшләү һәм аларны тормышка ашыруда катнашу.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы структурасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин